Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Антоновка авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№ 20-1 от 09.07.2021

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 11-4 номерлы карары, «Спас муниципаль районының Антоновка авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының 17.07.2019 70-1 номерлы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» Антоновка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итәргә:
- социаль наем шартнамәсе төзү;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) закон белән билгеләнгән вакытта бастырып чыгару турында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы Фролов В.С.